■ Изге бәйрәмебез

# КОРБАН ЧАЛУ ЙОЛАСЫ

**Рәсүл АБДУЛЛИН**

Корбан чалу Ибраһим галәйһиссәләм заманыннан безгә вәҗиб булып калган. Байлыгы булган һәр гаиләгә корбан чалу мәҗбүри. Йорт хуҗасы исеменнән корбан чалу күркәм. Корбан чалуның кирәклеге турында Коръәни Кәримдә - 108-че “Әл-Кәүсәр” (“Муллык”) сүрәсендә әйтелгән. Корбан чалыр өчен дөя, сыер, сарык, кәҗә, куй шикелле хайваннар яраклы. Әмма дөя - биш яшьлек, сыер - ике, сарык, куй, кәҗә бер яшьлек булырга тиеш. Куй белән сарыкның бәрәне гәүдәгә зур булып, 6 айдан арткан икән, аны да чалу дөрес. Әмма кәҗә бәтиен, гәүдәсе нинди булса да, бер яшь тулмыйча чалырга ярамый. Сарык, куй, кәҗә бер кеше өчен ният кылына. Ә дөя, сыер җиде кешегә ният кылына ала. Бер кеше үзен генә ният кылып, сыер чалса да, гөнаһ юк. Әгәр сыер, йә булмаса, дөяне җиде кеше берләшеп, корбан итеп чалалар икән, итне үлчәү ярдәмендә тигез итеп бүлү шарт. Без барыбер риза, ничек туры килсә дә ярый, дию дөрес түгел. Яки алты кеше корбан өчен, ә берәү ашау өчен генә кушылса, шулай ук дөрес булмый. Барысы да корбан өчен дип ниятли. Җиде кеше өчен бер сыер чалына икән, анда алтысы исән кеше өчен, берсе мәрхүм өчен дип ниятләсә, моны да шөбһәле дип әйтәләр. Димәк, сыер җидесе дә исән кеше өчен яисә җидесе дә вафатлар рухына ниятләнергә тиеш.

Чалына торган хайванның күзе сукыр булмасын, әгъзаларының да сәламәт булуы шарт. Колагы яки койрыгы өчтән бер өлешеннән дә зурырак киселгән булса, корбанга чалырга ярамый. Мөгезсез булса - ярый. Печкән хайванны корбанга чалу дөрес, Корбанлык малны гает көнне, гаеттән чыккач, гаетнең икенче, өченче көннәрендә чалу дөрес. Гаетнең өченче көнендә, кояш баеганнан соң, чалу инде дөрес булмый. Берәү корбанлык табалмыйчамы, йә булмаса, җае килмичәме, мал чалалмыйча калса, ул кеше мал бәһасен садака итеп өләшергә тиеш. Чалынган мал тиресен кеше үзенә тун тегәр өчен, йә булмаса, аяк киеме итеп эшкәртеп, файдаланса - дөрес, ә сату өчен кулланса - дөрес түгел. Каядыр тапшырса, акчасын садака итеп бирергә тиеш. Корбанга чалырга дип ниятләгән хайваннарның йонын алмасаң - әйбәтрәк. Инде йоны алынган икән, аны үз гаиләндә генә файдалану шарт, аның бер учы да сатылырга тиеш түгел. Йә сатып акчасын, йә йон килеш садака итеп бирсәң - ярый.

Корбан чалучы тәһарәтле һәм һичшиксез, геселле булырга тиеш. Иртәгә гает дигән көнне барыбыз да госелләнәбез. Госел ул: кеше тәһарәт ала, аягын гына юмыйча калдыра, шуннан соң бөтен җиренә су ирештереп баштан тотынып бөтен гәүдәсен өч мәртәбә юып чыга.Шуннан соң аягын юып тәмам итә. Менә бу госел коену була. Шулай тәһарәт-ләнгән, госелләнгән кеше корбан чала ала. Башка вакытта мал суйганда да геселле булу әйбәт. Корбан чалыр алдыннан корбан иясе яки бугазлаучы, хайванга карап, “Әл-Әнгам” (“Терлекләр”) сүрәсеннән бер аять укый:

- “Әллааһүммә иннә салəәтии үә нүсүкии үә мәхйәәйә үә мәмәәтии лилләәһи раббилгәәләмиинә ләә шәриикә ләһ” - “Әй, Аллаһ, тәхкыйк, минем намазым вә гыйбадәтләрем вә тереклегем һәм үлмәклегем барча галәмнең хуҗасы булган Аллаһ Тәгалә өчен вә Аның кодрәтендәдер. Ул Аллаһ Тәгаләнең һич шәрике юктырк”.

Шуннан соң: “Йа, Раббым, бер Үзеңнең ризалыгыңны өмет итеп, чала торган шушы корбанны фәлән улы фәләннән, Ибраһим галәйһиссәләмнән кабул итеп алган шикелле, кабул итеп ал”, - дип “Бисмилләәһи, Аллааһү әкбәр”, дип малны чаласың. Догасын гарәпчә укый алмаган кеше: “Йа, Раббым, бөтен кылган гыйбадәтләребез, укыган намазларыбыз, чалган корбаныбыз - барысы да Синең ризалыгың өчен генә, Синең һич тиңдәшең юк”, - дип әйтергә тиеш. “Йа, Раббым, Синең ризалыгыңны өмет итеп чалган шушы корбанны фәлән улы фәләннән, йә булмаса, фәлән кызы фәләннән, Ибраһим галәйһиссәләмнән кабул итеп алган шикелле, кабул итеп ал”, - дип, “Бисмилләәһи, Аллааһү әкбәр”, - дип, корбан чалганда берninди гөнаһ та юк.

Һәм инде ике ракәгать нәфел намазы уку киңәш ителә. Монысы мәҗбүри түгел. Кемнендер мөмкинлеге, вакыты булып, бер кеше, ике ракәгать намаз укый икән, анда һичнинди гөнаһ юк. Әй, намазы укылмады инде, дип кайгыру да һич урынлы түгел. Укыса - савабы була. Нәфел намазы ул биш вакыт намаз укучыга гына дөрес була. Шуңа күрә, корбан намазы укылмаган, дип борчылмагыз.




**Ғүмәр НӘБИУЛЛИН**

“Беҙҙең яҡта иң беренсе ҡорбанды Пәйғәмбәребеҙгә (уға Аллаһтың сәләме үә рәхмәте булһын), тип салырға кәрәк”, тейеүселәр бар. Шулай уҡ ҡайһы берәүҙәр: ҡорбанлыҡты аҫып тунарға ярамай, тип әйтәләр.

Һәр кем ҡорбанды Аллаһы ризалығы өсөн үҙе исеменән салдыра. Әгәр ҙә инде өҫтәмә рәүештә кемдер исеменән салаһы килә икән - ул ваҡытта икене сала.

Ә ҡорбанлыҡ Һарыҡты аҫып тунарға ярамай, тигәнде халыҡ үҙе уйлап сығарған. Аҫып тунаһаң, ҡорбанлыҡтың ҡаны ағып бөтөргә бик анһат. Был осраҡта ит таҙараҡ була, эште башҡарыу ҙа еңелерәк. Инде аҫып тунарға мөмкинлек булмаһа - быныһы икенсе хәл.

Хәләл асыҡ мәғлүм булды, үә харам асыҡ мәғлүм булды, ә улар араһында күптәр белмәй торған шикле нимәләр күп. Шуға ла шикле эштәрҙә һаҡланыусы кеше үҙен үҙ диненә һәм үҙ намыҫына ҡарата таҙа тота.

Әммә шикле нәмәләргә кереп киткән кеше, харам урын янында көтөүен йөрөтөп, харам урында малын көтөп үлән ҡабырға тыя алмаған көтөүсе кеүек, харам эштәргә бата.

Ысынлап та һәр батшаның үҙ “изге урыны” бар, һәм ысынлап та, Аллаһтың “изге урыны” - Уның тыйыуҙары.

Хәҡиҡәттә кеше тәненең шундай киҫәге бар ул сәләмәт булһа, бөтөн тән сәләмәт, әгәр ул ауырыһа, бөтөн тән ауырый. Ысынлыҡта был йөрәк. (Бохари һәм Мөслимдә килтерелә).

Ҡорбан ул бик мөһим ғибәҙәттәр һәм ул Ислам билгеләренән береһелер. “Кәүҫәр” сүрәһендә Аллаһы Тәғәлә намаҙҙың Аллаһтан башҡа бер затҡа бағышланмауы кеүек, ҡорбандың да Аллаһтан ғәйре бер затҡа бағышланмауы тураһында хәбәр итә. Былар түбәндәге аяттың асыл мәғәнәһелер: “Фасалли лираббикә үәнхәр”, йәғни “Раббыңа ғибәҙәт ҡыл үә ҡорбан сал” (Кәүҫәр сүрәһе 2-се аят). Башҡа бер аятта шул уҡ мәғәнәлә түбәндәге рәүештә бирелгән: “Тәхҡийҡ, минең уҡыған намаҙҙарым үә боғаҙланған ҡорбандарым фәҡәт Аллаһ ризалығы өсөн генә эшләнәләр үә тере булыуым һәм үлмәклегем бөтөн ғәләмдәрҙе тәрбиә ҡылыусы Аллаһы Тәғәлә эшелер”.

Хижрәнән һуң Рәсүлуллаһ (с.ғ.в.) Мәҙинәлә ун йыл дауамында йәшәгән һәм йыл һайын ҡорбан салған. Теләһә ҡайһы ҡалала йәшәгән, теләһә ҡайһы кешегә уның йолаһын үтәү тейешлелер. Рәсүлуллаһ (с.ғ.в.) кешеләргә был ғәмәл-ғибәҙәтте үтәп барырға ҡушып ҡалдырған. Нәҡ бына шуға күрә, Исламдағы күпселектең берҙәм фекеренсә, Ҡорбан ул - вәжиб ғәмәл-ғибәҙәт.

### ДОҒА:

**Раббәнәфтәх бәйнәнәә үә бәйнә ҡауминә бил-хаҡҡы үә әнтә хайрул-фәәтихиин.**

<u>Мәғәнәһе:</u> “Раббым! Минең менән хаҡлыҡта булған ҡауым араһын яҡшырт, күңелдәрен ас, дөрөҫлөктә Һин араларҙағы хәйерҙе, дуҫлыҡты, күңелдәрҙе асыусы Затһың”.

## КАЙДА БЕЗ “ТӘГӘРИБЕЗ”?

**Мөхәммәт НУРОВ**

*Кызык дөньябыз корылган:*
*Тәрәккыят алга атлый,*
*Ә кеше акылын жуя.*
*Ни кызганыч, бәләкәйдән,*
*Без калькулятордан башлыйбыз,*
*Бишне бишкә кушып баш ватмыйбыз:*
*“Нигә соң ул,!” - без аптырыйбыз.*
*Беләбезме, белмибезме,*
*“Көрәк” кулда, күздә пәрдә, кул ыргыта.*
*Үсә инсан, ә алдында башка аләт,*
*Гадәттән тыш ул акыллы,*
*Фәүкылгадә бер әкәмәт.*
*Дөрес, кемдер өчен ул кирәкле,*
*Әмма күпләр өчен, бик аяныч,*
*Ул каберташ төсле:*
*Акылның үсүе бетте*
*Һәм ялтырый “һәйкәл”.*
*Төне-көне чыкмас ул интернет чилтәреннән,*
*“Контакт”та рейтинг үстерә.*
*Әйтерсең лә, без барыбыз да “классташлар”?*
*Ә инде “асыя” безгә чын дус.*
*Кайда халык китап укып гыйлем җыйган чаклар,*
*Вә җор телле егетләр һәм кызлар,*
*Кайда урамнарда көне-төне уйнаган балалар,*
*Җавап гади, карты вә балачак,*
*Җәелеп утыралар өстәл каршысында,*
*Күзләр мониторда, кулда “тычкан”.*
*Әйтерсең дә, бөтен галәм акылыннан язган.*
*Сорау туа: кайда без “тәгәрибез”?*

## ХАҖ ГАМӘЛЕ

**Фәүзия ЗАГИТОВА**

*Бәхетлемен, шундый бәхетлемен*
*Кычкырасым килә тирә-ягыма.*
*Аллаһ бирде миңа мөмкинчелек*
*Мәккә шәһәренә барырга.*

*Ишетеп кенә белгән хаҗ гамәлен*
*Үз күзләрем белән күрдем мин.*
*Аллаһ бирде миңа көч һәм куат*
*Үзем барып гамәл кылдым мин.*

*Хаҗ гамәле кылу җиңел түгел,*
*Хаҗга хәзерләнеп барыгыз.*
*Үтәгез исламның 5че баскычын*
*Аллаһ кушканнарның барлык*
*фарызын!*

*Без бардык Минага, Арафатка,*
*Мөздәлифәгә,*
*Җамарадка таш атарга бардык.*
*Хаҗ юллары безгә ачык булды*
*Әзерәк чирләшеп тә алдык.*

*Ләкин чирләп ятарга вакыт юк.*
*Көтә безне алда зур сынаулар*
*Умра кылу, олы хажны кылу*
*Өхет тавы, Саур, Рәхмәт*
*дигән таулар.*

*Барысында күреп, йөреп чыгасы*
*бар,*
*Хаҗ гамәлләрен тулысынча*
*үтәсе бар,*
*Иртән торабыз да ашыгабыз*
*Әл-Хәрәмгә*
*Чөнки барып гамәл кыласы бар.*

*Ашыгып-ашыгып бардык*
*һәр намазга*
*Анда бер намаз тора*
*100000 намазга*
*Ятсак торсак уебызда гамәл*
*булды*
*Фаный дөньяны оныттык без*
*беразга*

*Тәһәрәт алып госел коендык та*
*Ихрам киемнәрен киеп алдык*
*Ният кылдык, намаз укыдык*
*Тәлбия әйтеп Әл-Хәрәмгә*
*юл алдык*

*Алда тора тәваф кылу,*
*сәгый кылу*
*Тапшырасың Аллаһка үзеңне.*
*Фәрештәләр әйтеп тора төсле*
*Атла бәндәм, алга бар,*
*йомма күзеңне.*

*Кулга-кул тотынып алга*
*киттек,*
*Әйтерсең лә умарта кортлары*
*өере,*
*Алга - тик алга атладык читкә*
*тайпылмый*
*Җиңеп чыктык шушы өерне.*

*Ете тапҡыр үттек Кәгъбә*
*тирәли,*
*Намаз укыдык Мәкам алдында*
*Зәм-зәм суы эчеп әзрәк*
*ял иттек тә*
*Киттек Сафа белән*
*Мәрва тавына*

*Сәги кылганда да укып йөредек*
*Белгән догаларның барсын да.*
*Күз алдына китердек*
*мәгъшәр көнен*
*Шулай киләбез дип*
*Аллаһ каршына.*

*Кемдер үтте көч-куатле булып*
*Кемдер килде көч-хәл белән.*
*Барыбыз да йөредек манма*
*тиргә батып,*
*Аллаһ кабул итсә иде дигән*
*уй белән*

*Аллаһ бирле безгә зур дәрәҗә*
*Мәккә, Мәдинә җирләренә*
*бара алдык*
*Шул дәрәҗәне төшермичә*
*Хаҗны җиренә җиткереп*
*кыла алдык.*

*Шөкер итәм Аллаһ сиңа гына*
*Хаҗияләр иттең безне дә.*
*Сорасагыз насип итәр*
*имандашлар*
*Хаҗ кылырга Аллаһ сезне дә*
*Әмин!!!*